**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КОЛЧУРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 13 апреле** **6№**

**Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегенең 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210 номерлы Федераль закон, 2019 елның 26 июлендәге Федераль мәгълүмати адреслы система турында мәгълүмат «Федераль адреслы система һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегенең 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2 номерлы карарының 1 нче кушымтасына (2019 елның 7 июнендәге 19 номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адрес- Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыру принциплары нигезендә һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай ук адресация объектын идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы билгеләүне үз эченә ала торган структуралаштырылган адресация объектының урнашу урыны тасвирламасы;»;

1.4 пунктның 14 абзацыни түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.) адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлегендә каралган башка объект;»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында rehttp://alkeevskiy.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Югары Колчура авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Е.В.Краснова